СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

15 ФЕВРАЛЬ, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 18 (8030) | Бәясе билгеләнгәнчә.

Бар яктан да уңганнар

Озак еллардан бирле комбайнчы булып эшләүче Владимир узган ел үзенә ярдәмче итеп Илгиз Әндәржановны алды. Тырыш егет шул ул, өстәвенә спортны да бик ярата. Грек - рим көрәше буенча Россия призеры булды, авыл Сабантуйларында гына түгел, районныкында да бил алышты, үз үлчәү категориясендә призлы урын тоткан егет ул. Ә спортны яраткан кеше ялкау, хезмәт сөймәс була алмый дип уйлады Владимир. Ул үзе дә бит Илгиз кебек үк үсмер вакытыннан волейбол уйнап үсте. Соңрак Чулпан волейбол командасы составында уйнады. Хезмәт сөю, үҗәтлек кебек сыйфатлар да нәкъ шул елларда ныгыды аның холкында. Беләкләре дә ныгыды егетнең, җир җимертеп эшләрлек булып житеште ул. Шулай булмаса, теләсә нинди модификацияле техниканы иярли алыр идеме?! Әнә, узган ел «ДОН - 1500» белән игеннәр уңышын җыюда ничек тырышып эшләде. Илгиз белән икәү көн - төн басудан кайтып кермәделәр. Тырышлыкның җимешләре дә мул булды: алар районның күп бөртек суктыручылар исемлегендә өченче булдылар.

Рәсемдә: «40 лет Победы» КФХАсы комбайнчысы В.Никитин ярдәмчесе Илгиз Әндәржанов белән.

Н.АЗИЗОВ фотосы.

Терлекчелек - көнүзәк өлкә

Кайда күпме сөт савалар?

Саннарның беренче баганасы - быелның 13 февраленда район хуҗалыкларында бер сыердан савылган уртача сөт, икенчесе - узган елның шул көнендәгедән артык яки ким (килограммнарда)

«Дуслык» ярд. хуҗ.	16,5	+4,5
«Кондырча»	15,7	+7,3
«Рассвет»	10,5	
«Сөлчә»	10,0	+2,8
Мичурин исем.	9,5	+2,2
«Родина»	9,0	+0,9
«Татарстан»	8,7	+1,8
Хафизов исем.	8,6	+1,0
М.Җәлил исем.	8,5	+2,1
«Чирмешән»	8,4	+1,8
«Заветы Ильича»	8,4	+1,4
«Якты Күл»	8,2	
«Восход»	8,1	+5,6
«Чишмә»	7,3	+1,7
«Төрнәс»	7,2	+2,2
Синдряков исем.	7,1	+1,1
«Үрнәк»	6,7	+1,7
«Заря»	6,5	+2,4
Кузнецов исем.	6,4	+0,7
«Москва»	6,3	+1,8
МСО ярд. хуҗ.	5,7	+1,2
«Игенче»	5,5	+0,7
Киекле	5,4	+0,5
«Мамык»	5,3	+1,3
Әлмәт	5,2	+0,6
«Правда»	5,0	+1,6
«Комбайн»	4,6	+1,1
«Таң»	4,1	
«Алга»	3,8	+1,0
Район буенча	**7,2**	**+1,6**

***

Бүген тулай савымны иң күп бирүче хуҗалык - Синдряков исемендәге крестьян - фермер хуҗалыклары ассоциациясе. Биредән һәр көнне 5030 килограмм сөт озатыла. Ә иң зур товарлылык - Киекледә, ул 89 процент.

ӨЧЕСЕ ДӘ ТЫРЫШ

Агриппина Илюхина, Лидия Васильева, Флера Фәйзуллина - сыер савучылар. Өчесе дә тәҗрибәлеләр, һәрчак үз алларына максат куеп эшлиләр. Шуңа хезмәт күрсәткечләре дә һәрчак күркәм. Әнә, Илюхина гыйнвар аенда үзе карый торган малларның һәркайсыннан 290 килограмм сөт савып алды. Бу - тулаем ассоциация буенча ин яхшы күрсәткеч.

Лидия белән Флера да алдынгы савучының үкчәсенә басып киләләр. Шундый савучыларның уртак тырышлыгы белән гыйнварда ассоциация буенча һәр сыердан савылган сөт тә 271 килограмм булды.

П.ИЛЮХИН,
«Родина» КФХАсы.

Былтыргыдан яхшырак

Кышлату чорын уңышлы дәвам итүче «Рассвет» КФХА терлекчеләре агымдагы елдан да уңышлы старт алдылар. Гыйнвар аенда, мисал өчен, хуҗалыктагы һәр сыерның уртача 279 килограмм сөт бирүенә ирешелде. Бу узган елның шул чорындагыдан 78 килограммга күбрәк.

Февральгә кергәч тә сөт саву кимемәде. Хәзер һәр сыердан уртача 10,5 килограмм сөт савылса, авылыбыз уңганы Халисә Сатдарова группасында бу күрсәткеч 13,3 килограмм тәшкил итә: тәҗрибәле савучының гыйнвар ае күрсәткече дә куанычлы, шушы чорда һәр сыердан 33,6 килограмм сөт савып алуны тәэмин итте ул.

Розалия Сөнгатуллина һәм Зәйнәп Сатдарова группаларында да савым югары.

Р.Галимов,
баш зоотехник.

Республикабызда

Мәгълүмат процесслары һәм технологиясе халыкара академиясендә ТРның беренче вице - премьеры Р.Моратов «Татарстанда экономик һәм социаль реформаның төп юнәлешләрен модельләү проблемалары» дигән темага «Экономик фәннәр докторы» дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклады.

***

Татарстан төзүчеләре 27 мартта тәүлек буе эш ташларга булды. Моның сәбәбен республика төзүчеләр профсоюзы комитеты рәисе Рифкат Кәримуллин бездәге төзүчеләрнең эшсез һәм акчасыз яшәве белән аңлата.

***

Казандагы Зәнгәр мәчеттән билгесез кешеләр һәрберсе 75әр мең сум торган Коръән китапларын урлап чыкканнар. Бу изге китапларны әлеге угрылар арзан бәягә сатарга мөмкин. Шундый шикле адәмнәрне күрсәгез, милициягә шалтыратырга кирәк.

Районыбыз хәбәрләр тормышыннан

Элемтә яңалыклары

НОРЛАТТА ДА ШӘҺӘРАРА ТЕЛЕФОН - АВТОМАТ

Өендә телефоны булган кеше хәзер санаулы минут эчендә ерак шәһәрләрдәге туганнары, якыннары белән телефон аркылы элемтәгә керә ала. Ә мондый мөмкинлегең булмаса? Билгеле инде, элемтә бүлегенең сөйләшү пунктына барасың, заказ бирәсең һәм... бер сәгать көтәсең. Ә кайчак... .

Ә менә күптән түгел гамәлгә кертелгән элемтәдәге яңа хезмәт - сөйләшү пунктына куелган шәһәрара телефон - автомат буенча коммутатор ярдәменнән башка да санаулы минутлар эчендә код буенча Бәйсез Дәүләтләр Берлегенең теләсә кайсы шәһәре белән һичнинди проблемасыз элемтәгә керергә мөмкин. Сөйләшү өчен жетон эзләп азапланасы да түгел, акчаны пункттагы кассирга түлисе генә кала.

Шунысын да әйтергә кирәк, әлегә пунктта мондый телефон икәү генә. Узел администрациясе исә киләчәктә аларның санын арттырырга ниятли.

Телефоннар бик кирәк

Җәмәгать урыннарында, урамнардагы таксофоннар халык өчен бик уңайлы. Әмма аларның еш ватылулары (дәресрәге, ватулары) безне бу уңайлыктан мәхрүм итә иде. Ә менә соңгы вакытта элемтә бүлегенең шәһәребезнең барлык микрорайоннарына, җәмәгать урыннарына төзүчеләрнең элемтә объектларын тапшыруларына бәйле рәвештә таксофоннар урнаштырырга ниятләвен халык хуплап каршы алды. Әле күптән түгел генә район элемтә узелының сөйләшүләр пунктына ике яңа таксофон урнаштырылды. Тимер юл һәм автовокзаллардагы таксофоннардан да халык теләп файдалана.

МӘГАРИФ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

Февраль - хокук айлыгы

Район мәгариф бүлеге планы нигезендә февраль ае хокук айлыгы буларак игълан ителде.

Әлеге айлык рамкасында мәктәпләрдә хокукый лекторийлар, хокук темасына багышланган класстан һәм мәктәптән тыш чаралар, хокук саклау органнары хезмәткәрләре белән очрашулар үтәчәк.

Җырлыйлар да, биилә дә

Бу көннәрдә мәктәпләрдә үзенчәлекле шау - шу - үзешчән сәнгатьтә катнашучылар смотры бара. Әлегә ул класслар арасында оештырыла, аннан кустларда үтәчәк. Ә «иң - иң»нәр озакламый район смотр конкурсында билгеле булачаклар

Кыска хәбәрләр

Тикшерү башланды

Дәүләт орлык инспекциясендә район хуҗалыкларындагы чәчүлек орлыкларны чәчү алды тикшерүе башланды. Иң беренче булып үз орлыкларын тикшертергә «Дуслык» ярдәмче хуҗалыгы китерде.

Чистайга, ярышка

Бүген Чистайда уза торган «Татар жыры - 97» республика зона конкурсында безнең һәвәскәрләр дә көч сынашачаклар. Алар - Норлат балалар музыка мәктәбе вокаль ансамбле, Кәкре Атаудан Фәүзия Кәлимуллина, Норлаттан Нәкыя Мусина.

КӨН ТӘРТИБЕНДӘ - КОЛЛЕКТИВ КИЛЕШҮ

Шушы көннәрдә агропромышленность комплексы работниклары профсоюзы район комитеты президиумының чираттагы утырышында 1996 елда профсоюз бюджетының үтәлеше мәсьәләсе каралды.

АПК профсоюз оешмалары (ә алар районда 58әү) агымдагы елга коллектив килешүләр төзүдә һәм кабул итүдә дә инициаторлар булырга тиешләр. Бу җәһәттән район авыл хуҗалыгы идарәсе һәм тармак профсоюзы район комитетының берләштерелгән карары бар. Коллектив килешүләрне КХА һәм предприятиеләрнең гомуми жыелышында 1 мартка кадәр карап кабул итәргә тәкъдим ителә. Анда производство планнарын реализацияләү һәм житештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча практик чаралар да каралырга тиеш. Хезмәтне саклау һәм аңа түләү, алдынгыларны бүләкләү, өстәмә отпускылар, кадрлар политикасы - әлеге документларның берсе дә мондый пунктлардан башка узмый.

Киңәшмәдә социаль - экономик проблемалар: эшләүчеләрне торак белән тәэмин итү, медицина һәм санатор - курорт дәвалавы, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү дә аерым урын алып торалар.

Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

ТАТАР АЛФАВИТЫН ТӘРТИПКӘ КИТЕРҮ ТУРЫНДА

Әлеге Закон татар алфавиты төзелешенең фәнни нигезләрен тагын да камилләштерү һәм тәртипкә китерү максатларында кабул ителә.

1 статья. Әлеге Законда татар алфавиты дигәндә билгеле бер тәртиптә урнашкан татар теле хәрефләре җыелмасы аңлашыла.

2 статья. Ә, Ө, Ү, Җ, Ң, Һ хәрефләренең татар алфавитында урнашуын түбәндәгечә билгеләргә:

Ә хәрефе А хәрефеннән соң, Ө хәрефе - О хәрефеннән, Ү хәрефе - У хәрефеннән, Җ хәрефе - Ж хәрефеннән, Ң хәрефе - Н хәрефеннән, Һ хәрефе - Х хәрефеннән соң куела.

3 статья. Әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, татар алфавитын 38 хәрефле итеп, түбәндәге тәртиптә һәм әйтелештә расларга:

Баш хәрефләр	Юл хәрефләр	Хәрефнең әйтелеше
А	а	а
Ә	ә	ә
Б	б	бә
В	в	вә
Г	г	гә
Д	д	дә
Е,Ё	е,ё	е,йо
Ж	ж	же
Җ	җ	җә
З	з	зә
И	и	и
Й	й	й кыска
К	к	ка
Л	л	эль
М	м	эм
Н	н	эн
Ң	ң	эң
О	о	о
Ө	ө	ө
П	п	пә
Р	р	эр
С	с	эс
Т	т	тә
У	у	у
Ү	ү	ү
Ф	ф	эфф
Х	х	ха
Һ	һ	һе
Ц	ц	цә
Ч	ч	чә
Ш	ш	ша
Щ	щ	ща
Ъ	ъ	ъ калынлык һәм аеру билгесе
Ы	ы	ы
Ь	ь	ь нечкәлек һәм аеру билгесе
Э	э	э
Ю	ю	ю
Я	я	я

4 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Законны үтәү буенча тиешле карарлар кабул итәргә.

5 статья. Татарстан АССР Югары Советы Президиумының 1939 елның 5 маендагы «Татар язуын латинлаштырылган алфавиттан рус графикасы нигезендәге алфавитка күчерү турындагысы» Указын әлеге Закон гамәлгә кергән көннән үз көчен югалткан дип санарга.

6 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көннән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Президенты **М.ШӘЙМИЕВ.**

Казан шәһәре,
1997 елның 20 гыйнвары.

Күптән килгән даны бар



Солтан ага белән Хатирә апа Миндубаевларның ишле гаиләсендә өлкән ир бала булып үсте Шәүкәт. Тыйнак, эшчән булып үсте. Яшьтән тракторга утырды, аның төрле маркадагыларын иярләде. Намуслы хезмәте өчен рәсеме «Алга» колхозының Мактау тактасыннан төшмәде, ул күп конференцияләр, алдынгылар форумына вәкил итеп җибәрелде. Шәүкәт Солтановичның шәхси архивында бүген күпсанлы жиңүче значоклары, Мактау грамоталары, аның хакында газета язмалары кадерләп саклана. Болар - аның хезмәт биографиясенең истәлекле мизгелләре.

Миндубаев хәзер дә хуҗалыкның ышанычлы, унган механизаторлары исәбендә, Т - 70 тракторын иярли, чөгендер игү звеносын житәкли. Татлы тамырны чәчү, эшкәртү, көзен БМ - 6 белән яфрак урдыру - боларның һәммәсен жиренә житкереп башкарырга күпгән гадәтләнгән инде ул.

Рәсемдә: «Алга» КХАсы механизаторы Ш.С.Миндубаев. Н.АЗИЗОВ фотосы.

Яфраклары яшел ак каенның
Хәтфә жәйгән кебек һәр ягы.
Әйләп - бәйләп уйный яшь балалар
Гөрләп тора һәр көн тау яны...

Зыя Ярмәки оныгы безнең мәктәптә эшли

Бала чагыбызның юлдашы булган, халык жырына әверелгән бу шигъри юллар серле моң белән уралып, кайсыбызның гына күңелләрен дулкынландырмый һәм моңландырмый икән?

Шәһәрнең өченче мәктәбенең 5 нче а класс укучылары үзләренең чираттагы класс сәгатен шушы «Ак каен» жыры белән баашлап жибәрделәр. Класс житәкчесе Фәния Насыйховна жырның авторы Зыя Шәйхи улы Насыйровның (Ярмәкинен) безгә күрше Самара өлкәсе Иске Ярмәк авылында туып үсүен һәм бу елның гыйнвар аенда аның тууына 110 яшь тулуын сөйләп үтте, шагыйрьнең «Кайчакта», «Теләк» шигырьләрен укыды. Ә иң кызыклысы алда иде. Класс сәгатенә кунакка чакырылган мәктәпнең чит телләр укытучысы Попкова София Наилевна Зыя Ярмәкинен оныгы (улы Наилнең кызы) икән.

Жыр тәэсиреннән дулкынланган София Наилевна үзенең сүзләрен «Балалар, мин Зыя Ярмәкине язучы буларак түгел, ә бабам буларак беләм һәм яратам», - дип башлап китте. Ул бабасының тормышы - язмышы белән балаларны якыннан таныштырды. Очрашуга гаилә альбомыннан күп кенә истәлекле фоторәсемнәр дә альш килгән иде. София Наилевна бабасының укымышлы кеше булуын - Чистай, Уфадагы «Галия» мәдрәсәләрендә укуын һәм туган авылында балалар укытуын сөйләде. Октябрьдән соңгы болганчык елларның кырыс жилләре (ул еллардагы бик күп укымышлы кешеләрнең башыннан үткән фажига) бабасы Зыяның да язмышына кагылып үтә. Зыя Ярмәки туган авылын ташлап, 1931 нче елның ахырында Үзбәкстанга күчеп китәргә мәжбүр була. Ә әбисе (Зыя Ярмәкинен тормыш иптәше) 8 бала белән авылда ялгыз кала. Ялгыз хатынга 8 бала тәрбияләү бик авыр була, шул елларда ул 5 баласын югалта. Калган өч баласын иярткән, әбисе дә Иске Ярмәктән ире янына - Үзбәкстанның Фирганә өлкәсе Ташлак авылына күчеп китә.

София Наилевна бабасының һәм әбисенең шул китүдән туган авыллары Иске Ярмәккә бер тапкыр да әйләнеп кайтмауларын әйтте, моны бабасының күңелендә шул еллардагы хакимият ияләренә үпкә, гаделсезлеккә рәнжү тою нәтиҗәседер дип аңлатты.

Зыя Ярмәкинен Үзбәкстандагы каберенең фоторәсемен карагач, күңелгә шундый уйлар килде. Сагынгандыр шагыйрь якташыбыз үзенең Сок елгасы белән уратып алынган Юкәле таулы туган төбәге - Иске Ярмәк авылын, шул ак каеннары белән сагынгандыр. Ә «Ак каен» жыры бүген дә жырдагыча, табигатьнең үзе кебек матур, һаман серле, яңа булып яңгырый алган жыр ул.

Ап - ак каен, - инде бик карт каен,
Бизәлә ул язлар килгәндә.
Яшел яфрак яра һәр ел саен,
Кояш жылы нурлар сипкәндә, - дип жырлап тәмамладылар укучылар бу очрашуны.

Ч.ЯРУЛЛИНА,
3 нче мәктәп директорының укыту - тәрбия эшләре буенча урынбасары.

БАЛАЛАРЫБЫЗ АТЛЫГЫП ТОРСЫНГА

Бирегә килеп кергән саен аны гайчандыр, 50 нче елларда үзебез йөргән поселок балалар бакчасы белән чагыштырмый калмыйм. Безнекендә нәниләр өчен китаплар торган жыйнак кына шкаф та зур байлык санала иде, ә монда - күзеңнең явын алырдай жиһазлар, йомшак келәмнәр, пәрдәләр эленгән зур һәм якты тәрәзәләр, пианино, хәтта аквариум да бар. Ә инде шуларга биредә эшләүче тәрбиячеләрнең ягымлылыгы, балаларга карата бик йомшак мөнәсәбәте дә кушылгач, сабыйларның һәр иртәсе дә куаныч белән башланып китә, балаларын көне буена биредә калдыручы ата - аналарның да күңелләре тыныч. Сүзем - Норлаттагы «Теремок» балалар бакчасы турында. Алевтина Ивановна Ежова да шушында эшли. Элек ул монда өлкән тәрбияче булган, хәзер мәдирнең тәрбия - белем бирү эше буенча урынбасары булып санала. Балалар бакчасының бусагасыннан атлап кергән һәр кеше биредә аның житәкчелегендә һәм үз куллары белән башкарылган бик күп эшләргә игътибар итми калмый. Берсеннән берсе ачык төстәге буяулар белән ясалган күпсанлы чәчәкләр, башка рәсемнәр - барысы да балаларның игътибарын да тарта, аларда матурлыкны тоя белү хисе дә уята.

Алевтина Ивановнаның язмышы гади генә. Норлатта хезмәт, шул исәптән кул эшләре дә хөрмәттә булган Козловлар гаиләсендә үсә ул. Әтисе Иван Егорович һәвәскәр генә саналса да плакат каләме һәм рәссам пумаласы тота белә һәм заманында районда бер генә тантана да аның кулы белән язылган лозунглардан башка узмый торган иде. Әнисе кисү - тегү эшенә оста булды. Ул елларда яхшы күлмәклек табу да кыен иде бит һәм алар ситсыны Мәскәүдән кадәр кайтарта иделәр. Һәм яшьтәш кызлары кич чыгып киткәндә Аля апалары белән бергә өйдә утырып әнисеннән тегү осталыгына өйрәнә. Шул чакта берочтан чигү, рәсем ясарга да өйрәнә. Чистай педучилищесын бетергәч шикәр заводы балалар бакчасында эшли, аннан инде «Теремок»ка күчә. Шулай итеп, 29 елга якын вакыт узып та киткән, ә менә яраткан эшенә мәхәббәте, сабырлыгы һич тә сүрелмәгән. Шуңадыр, кызы Лена да әнисе сукмагыннан китте: училище бетереп инде 3 нче ел бала - чага арасында мәш килә, әле башкалага барып югары уку йортына психологлыкка укырга да кереп кайтты. Шулай ук киеем дә кисеп тегә, үзе дә бар фантазиясен жигеп төрле модельләр уйлап чыгара. Хатын - кызга тормышта моның һич артыгы юк бит.

Дәресен генә әйткәндә, Алевтина Ивановнаның балалар бакчасындагы бу уйлап табулары һич тә юктан гына башланып китмәгән. Рәсем программасы буенча балаларны төрле нәкышлар белән таныштыру да каралган. Нәтиҗәдә әллә никадәр альбомнар, төрле уенчыклар ясалды. Аннары бакчаны да кешегә ялынмый, үз куллары белән бизәргә ниятли. Башта холлның ике диварына рәсемнәр ясый, аннан түшәм кырыйларын һәм баскыч култыксаларын бизәргә алына. Нәкышләрне төрле открыткаларда күргән трафаретлар буенча төшерсә, фоннарын бизәргә хезмәттәшләре бердәм булып ярдәм итәләр. Бер кызып киткәч тышкы ишекне, музыка занятиеләре уза торган залны да бизәп ташлый. Кайбер эшләргә, кем әйтмешли, аптыраганнан тотынырга туры килә. Бервакытны шулай аслары ишексез шкафлар алып кайталар бакчага һәм Алевтина күп уйлап тормый, ул бушлыкны каплау өчен макраме үрергә тотына...Аннары чират тәрәзә пәрдәләренә житә. Шулай итеп, тоташ бер ансамбль килә дә чыга...

Билгеле инде, болар һәммәсе күп вакыт, хезмәт сорый, пөхтәлек таләп итә. Әмма бер тотынсаң, дип сөйли Алевтина Ивановна, эшеңне ничек тә тизрәк төгәлләп, башкаларны да куандырып, үзеңне дә сөендерәсең килә башлый.

Матурлык кешеләргә шатлык бүләк итә, дибез. Күптәннән әйтелгән булсалар да, бу сүзләрнең мәгънәсе һаман да шул ук. Балалар бакчасында эшләүче Алевтина Ивановна кебек бик күпләрнең балаларыбызның икенче өйләрен алар анда атлыгып барырдай итү теләгә төсле.

Т.НАЗАРОВА.

TV

ПОНЕДЕЛЬНИК 17 ФЕВРАЛЯ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан»
18.10 Мультфильмы
18.30 Балалар өчен «Тамчы»
18.45,20.45 «Җиһан»
19.00,20.00 «Итальянский контракт». Х/ф.
19.45,21.45 Новости
20.30 «Әлли - бәлли - бәү»
21.00 Зиннур Гыйбайдуллин җырлары
22.00 «У зеленого камина». Братья Акчурины

ОРТ

15.00 18.00 23.25 Новости
16.00 Звездный час.
16.40 «Нико и его друзья». Молодежный сериал.
17.10 ...До шестнадцати и, старше.
17.35 Вокруг света.
18.15 «Девушка по имени Судьба».
19.05 Погода.
19.10 Час пик.
19.35 «Угадай мелодию».
20.00 Понедельник с Познером.
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45 «Полтергейст» .
22.40 «Театр+TV». Алла Демидова.
23.35 «Месть» Х.ф
1.25 Пресс-экспресс.
1.45 Программа передач.

«РОССИЯ»

6.00 Ноу хау.
16.25 «Домашний доктор».
16.30 Новое пятое колесо.
17.00 20.00 23.00 Вести.
19.55 Реклама.
20.35 Ночная жизнь городов мира. Копенгаген.
21.10 «Санта-Барбара».
22.05 Погода на завтра.
22.10 Добрый вечер.
23.30 «На коне». Телелотерея.
23.55 «Дежурная часть».
0.10 «Молодость театра». К 75-летию театра имени Е.Б.Вахтангова.
1.00 «Шоу долгоносиков».

РИО

18.20 «Особо важные персоны».
18.35 РТР. «Клубничка».
19.05 Студия «ДВА».
19.55 21.00 23.45 Шесть новостей.
20.05 «Музыка и пресса»: «Акулы пера» - группа «Лицей».
21.15 Х/ф «Выйти замуж за капитана».
23.15 Катастрофы недели.
00.00 Дорожный патруль.

ВТОРНИК, 18 ФЕВРАЛЯ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан».
18.10 Мультфильмы
18.45, 20.45 «Җиһан»
19.00 «Авыл»
19.30 «Среда обитания». Тропою зимней, заповедной...
19.45,21.45 Новости
20.00 «Театр сәхифәләреннән». Ш.Сарымсаков
20.30 «Әлли - бәлли - бәү»
21.00 «Язмыш». Т/ф.
21.15 «Стиль - 7»
22.00 «Под созвездием Лиры»

ОРТ

6.00 «Доброе утро»
9.00 12.00 15.00 18.00 23.35 Новости.
9.15 18.15 «Девушка по имени Судьба».
10.35 Смехопанорама.
11.10 Мультфильм.
11.30 19.35 «Угадай мелодию».
12.10 «Семнадцать мгновений весны».
13.20 Человек и закон
13.45 Мультфильм.
13.55 КВН-ассорти.
14.15 «Загадки истории».
15.20 «Альберт - пятый мушкетер».
15.45 Кварьете «Веселая квампания».
15.55 Мультитроллия.
16.10 Волшебный мир, или Синема.
16.40 «Нико и его друзья».
17.10 ...До шестнадцати и старше.
17.35 Вокруг света.
19.05 Погода.
19.10 Час пик.
20.00 Тема.
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45 «Частный детектив, или Операция «Кооперация» Х.ф
23.45 Хит-парад.
0.25 Пресс-экспресс.
0.35 Программа передач

«РОССИЯ»

7.00 Утренний экспресс.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.15 Мультфильм.
8.25 18.40 «Клубничка».
8.55 «Дорогая редакция».
9.20 «Аншлаг» представляет.
9.45 В мире животных.
10.15 ,21.10 «Санта-Барбара».
11.15 Мультфильм.
11.25 «Деловая Россия».
12.05 «За околицей».
14.25 «Призраки зеленой комнаты». Х.ф
15.40 «Памяти Врубеля». Д.ф
16.00 «Врача вызывали?».
16.25 «Манекен».
16.30 Ваше право.
17.15 «Иванов, Петров, Сидоров и другие».
17.55 Там-там новости.
18.05 Лукоморье.
18.25 Посмотри на себя.
19.10 Момент истины
19.40 VIP
19.55 Реклама.
20.35 «Аншлаг» представляет.
22.05 Погода на завтра.
22.10 Добрый вечер.
23.30 Телевизионный театр. И.Бунин. «В Париже».
0.10 Горячая десятка.
1.05 Только для взрослых.
1.15 «Товары - почтой»

РИО

18.20 РТР. Особо важные персоны.
18.40 РТР. Телесериал «Клубничка».
19.10 «Студия ДВА».
19.55 21.00 Шесть новостей.
20.05 Ток-шоу «Профессия»: «Писатель-фантаст».
21.15 Вавилон-5", 52 серия.
22.05 Те Кто.
22.35 «Держи вора». Сериал, 4 серия.
23.30 Шоу Бенни Хилла.
00.00 Дорожный патруль.

СРЕДА, 19 ФЕВРАЛЯ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан»
18.10 Мультфильмы
18.45, 20.45 «Җиһан»
19.00 «Халык җәүһәрләре». Флера Сөләйманова
19.35 «Чудесные башмачки». Т/ф.
19.45, 21.45 Новости
20.00 «Служба 01»
20.15 «Пульс»
20.30 «Әлли - бәлли - бәү»
21.00 Музыкаль тәнәфәстә
21.10 Р.Харис. «Шаһыйрь йөрәге»
22.00 «Яңа елда яңа җыр»

ОРТ

6.00 «Доброе утро»
9.00 12.00 15.00 18.00 23.35 Новости
9.15 ,18.15 «Девушка по имени Судьба».
10.00 Тема
10.40 «В мире животных»
11.15. Мультфильм.
11.30 ,19.35 «Угадай мелодию».
12.10 «Семнадцать мгновений весны».
13.25 Мультфильмы.
14.00 КВН-ассорти
14.20 «Загадки истории».
15.20 «Альберт - пятый мушкетер».
15.45 Кактус и К.
15.55 До-ми-соль.
16.10 Зов джунглей.
16.40 «Нико и его друзья».
17.10 ...До шестнадцати и старше.
17.35 Вокруг света.
19.05 Погода.
19.10 Час пик.
20.00 «Чтобы помнили...»
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45 «Максим Перепелица» Х.ф
23.45 Пресс-клуб.
0.35 Программа передач.
0.50 Пресс-экспресс.

«РОССИЯ»

7.00 Утренний экспресс.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.15 9.20 10.55 11.1 5 1.10 «Товары - почтой».
8.25 «Клубничка».
8.55 «Дорогая редакция».
9.30 23.35 «Городок».
10.05 21.10 «Санта-Барбара».
11.25 «Деловая Россия».
12.05 «За околицей».
12.20 Момент истины.
12.50 «Эксповестник».
12.55 «Автограф».
13.00 «К-2» представляет: А.Герман в программе «Абзац».
13.55 «Магазин недвижимости».
14.25 «Солдат Иван Бровкин на целине». Х.ф
16.00 Частная коллекция.
16.25 «Эксповестник».
16.30 Образ жизни.
17.15 «Иванов, Петров, Сидоров и другие».
17.55 Там-там новости.
18.05 Лукоморье.
18.25 Посмотри на себя.
19.10 Парламент.
19.40 VIP
19.55 Реклама.
22.05 Погода на завтра.
22.10 Добрый вечер.
23.30 Богема. Беата Тышкевич.
0.10 Блок-нот.
1.00 «Только для взрослых».

РИО

19.10 «Студия «ДВА».
19.55, 21.00, 00.45 Шесть новостей.
20.05 Ток-шоу «Я сама»: «Здравия желаю».
21.15 «Вавилон-5», 56 серия.
22.05 Те Кто.
22.35 «Держи вора». 5 серия.
23.30 Шоу Бенни Хилла.
00.20 Дорожный патруль.

ЧЕТВЕРГ, 20 ФЕВРАЛЯ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан»
18.10 Мультфильмы
18.45,20.45 «Җиһан»
19.00 «Фани дөньяны бакый кылдың». Рәссам Б.Урманченың тууына 100 ел тулуга багышлана
19.25 «На фондовом рынке РТ»
19.45,21.45 Новости
20.00 «ГАИ - информ»
20.10 Раил Бикбаев җырлый
20.30 «Әлли - бәлли - бәү»
21.00 Г.Исхакый. «Тормышмы бу?»
22.00 «Шесть песен на бис». С.Пенкин.

ОРТ

6.00 «Доброе утро»
9.00 12.00 15.00 18.00 23.35 Новости.
9.15 18.15 «Девушка по имени Судьба».
10.00 «Чтобы помнили...» Леонид Быков. Ведущий-Л.Филатов.
10.40 «Клуб путешественников»
11.25 Мультфильм.
11.35 Смак
12.10 «Семнадцать мгновений весны».
13.20 Мультфильмы .
13.55 КВН-ассорти.
14.15 «Загадки истории».
15.20 «Альберт - пятый мушкетер».
15.45 Остров Чунга-Чанга
16.10 Тин-Тоник.
16.40 «Нико и его друзья».
17.05 Рок-урок.
17.35 Вокруг света.
19.05 Погода.
19.10 Час пик.
19.35 Джентльмен-шоу.
20.00 «Моя семья».
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45 «Ночной дозор» Х.ф
23.45 «Сиреневый туман». Музыкальная программа.
0.25 Пресс-экспресс.
0.35 Программа передач.

«РОССИЯ»

7.00 Утренний экспресс.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести
8.15 9.20 10.55 11.15 1.20 «Товары - почтой».
8.25 18.40 «Клубничка».
8.55 «Дорогая редакция».
9.30, 20.35 Сам себе режиссер.
10.05, 21.10 «Санта-Барбара».
11.25 «Деловая Россия».
12.05 «За околицей».
12.20 Двойной портрет.
12.50 «Ваш партнер».
12.55 «Автограф».
13.00 Мужчина и женщина.
13.40 Репортер.
13.55 «Магазин недвижимости».
14.25 «Красавец-мужчина». Х.ф
15.35 «И слышно было вдалеке...» Д.ф
16.00 На пороге века.
16.25 «Эксповестник».
16.30 «Анонимные собеседники».
17.15 «Иванов, Петров, Сидоров и другие».
17.55 Там-там новости.
18.05 Лукоморье.
18.25 Посмотри на себя.
19.10 Момент истины
19.40 VIP
19.55 Реклама.
22.05 Погода на завтра.
22.10 Добрый вечер.
23.30 Баскетбол. ЦСКА-"Шарлеруа"(Бельгия).
0.30 Адамово яблоко.
1.10 «Только для взрослых».

РИО

18.35 РТР. Телесериал «Клубничка».
19.05 Студия «ДВА».
19.55 ,21.00, 23.45 «Шесть новостей».
20.05 «Сделай шаг».
21.15 «Вавилон-5», 54 серия.
22.20 Те Кто.
22.50 Сериал «Держи вора». 6 серия.
23.35 Шоу Бенни Хилла.
00.00 Дорожный патруль.

ПЯТНИЦА, 21 ФЕВРАЛЯ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан»
18.10 Мультфильмы
18.45,20.45 «Җиһан»
19.00 «В Госсовете Татарстана»
19.35 «Связь без границ»
19.45,21.45 Новости
20.00 «Досье 02»
20.15 Хәснул Вәлиуллин җырлары
20.30 «Әлли - бәлли - бәү»
21.00 «Җомга көн кич белән»
22.00 «Видеоспорт»
22.20 «На балу у Музыки»

ОРТ

6.00 «Доброе утро»
9.00 12.00 15.00 18.00 23.50 Новости.
9.15, 18.15 «Девушка по имени Судьба».
10.05 «Моя семья».
10.45 Пока все дома.
11.20 Мультфильм.
11.30 Играй, гармонь любимая!
12.35 «Семнадцать мгновений весны».
13.55 КВН-ассорти.
14.15 «Загадки истории».
15.20 «Альберт - пятый мушкетер».
15.55 Лыжи. Чемпионат мира.
17.30 Магия: мир сверхъестественного.
19.10 Погода.
19.15 Человек и закон.
19.45 Поле чудес.
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 Программа передач.
21.45 Коломбо в детективе «Как совершить убийство».
23.10 Взгляд.
23.50 Новости
0.05 «Уроки улицы» Х.ф
1.45 Пресс-экспресс.
2.05 Программа передач.

«РОССИЯ»

7.00 Утренний экспресс.
8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
8.15 «Медицинский вестник».
8.25 ,18.40 «Клубничка».
8.55 «Дорогая редакция».
9.20 ,10.55 «Товары - почтой».
9.30 L-клуб.
10.05, 21.10 «Санта-Барбара».
11.15 Торговый дом «Ле Монти».
11.30 «Деловая Россия».
12.10 «За околицей».
12.25 «Палиха, 14».
12.30 «Автограф».
12.35 14.20 Чемпионат мира по лыжным видам спорта.
13.55 «Магазин недвижимости».
14.50 «Красавец-мужчина». Х.ф
15.50 «Ярославский портрет». Д.ф
16.00 Соотечественники.
16.25 «Эксповестник».
16.30 Арена для сенсаций.
17.15 «Иванов, Петров, Сидоров и другие».
17.55 Там-там новости.
18.05 Лукоморье.
18.25 Посмотри на себя.
19.10 "Високосный год."
19.40 VIP
19.55 Реклама.
20.35 L-клуб.
22.05 Погода на завтра.
22.10 Добрый вечер.
23.30 Ночной экспресс.
0.10 Кинозал «К-2». «Все люди смертны». Х.ф

РИО

18.20 Особо важные персоны.
18.35 Телесериал «Клубничка».
19.05 Главная новость недели.
19.30 21.25 22.35 Шесть новостей.
19.40 Х/ф. «В зоне особого внимания». 2
21.40 Клуб «12 копеек».
22.05 Х/ф. «Ответный ход».
00.50. Дорожный патруль.

СУББОТА, 22 ФЕВРАЛЯ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан»
18.00 Мультфильмы
18.45 «Җиһан»
19.00 «Опера сәхнәсе осталары». Венера Ганиева
19.45 Новости
20.00 Из «личной жизни»...дома
20.05 «Нәфис сүз кичәсе». Ә.Еники. «Матурлык»
20.30 «Әлли - бәлли - бәү»
20.40 Р.Вәлиев. «Яшисе килә»

ОРТ

7.55 «Юнга Северного флота» Х.ф
9.25 Премьера мультсериала.
9.45 Домашняя библиотека.
10.00 15.00 18.00 Новости.
10.10 Слово пастыря. Митрополит Кирилл.
10.30 Не зевай!
11.00 Утренняя почта.
11.35 Смак.
11.55 Приглашение к музыке.
12.25 «По улицам комод водили» Х.ф
13.40 Умники и умницы.
14.30 Очевидное - невероятное.
15.20 Лыжи. Чемпионат мира. Двоеборье.
15.45 Михаил Жванецкий, Инна Чурикова, Нина Ананиашвили в программе «Созвездие «Триумф».
16.40 В мире животных.
17.10 «Колесо истории».
18.20 КВН - ассорти.
18.50 Погода.
18.55 «Золотая серия». «Не может быть!» Х.ф
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.50 Программа передач.
21.55 «Сегун».
23.00 «Каламбур».
23.30 «Путешественник» Х.ф
1.40 Программа передач.

«РОССИЯ»

8.00 «Балерина на корабле». Мультфильм.
8.25 «Фрам - полярный медведь».
9.15 Тележурнал «Здоровье».
9.25 «Живы будем...» Д.ф
10.15 «Клуб «Адреналин».
10.30 По вашим письмам.
11.00 14.00 20.00 Вести
11.30 Парламентская неделя.
12.15 «Красная книга». Экологическая экспедиция РТР.
12.30 Лучшие игры НБА.
13.30 «Анонимные собеседники».
14.20 «Молодой Пикассо».
15.10 Диалоги о животных.
15.40 «Дождевые псалмы». Поет О.Басилашвили.
15.55 21 кабинет.
16.25 «Поэт в России - больше, чем поэт». Программа Е.Евтушенко.
16.50 Бесконечное путешествие.
17.20 «Темная» для...»
17.35 Субботний вечер российского телевидения.
17.50 «Экипаж Леонида Филатова».
18.55 Аншлаг и Ко.
20.50 «Беги.» Х.ф
22.25 Погода на завтра.
22.45 Совершенно секретно.
23.40 Чемпионат мира по лыжным видам спорта.
0.10 Репортер.
0.40 Программа «А».
1.35 «В той области небес». Х.ф

РИО

15.20 19.40 «Адъютант его превосходительства».
18.40 Домовой.
19.00 22.45 Шесть новостей.
19.10 Скандалы недели.
22.55 Шоу Ивана Демидова.
23.30 Дорожный патруль.

ВОСКРЕСЕНЬЕ, 23 ФЕВРАЛЯ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан»
18.05 Р.Батулла. «Салават күпере»
18.50 Певец и поэт Геннадий Мигачев - Жан Д.Алевье
19.30 «ТОН»
20.15 «Автокалейдоскоп»
20.30 «Әлли - бәлли - бәү»
20.40 «Телебуклет»
20.50 «Сугышның ике көне»
22.00 Сиринә Латыйпованың иҗат кичәсе

ОРТ

7.50 Николай Черкасов в фильме «Суворов».
9.35 Мультфильмы нашего детства.
10.00 15.00 23.45 Новости.
10.15 «Непутевые заметки» Дм.Крылова.
10.30 Пока все дома.
11.10 Утренняя звезда.
12.00 Служу России!
12.30 Играй, гармонь любимая!
13.00 Провинциальные истории.
13.30 Сериал «Подводная одиссея команды Кусто».
14.25 Смехопанорама.
15.20 Возвращение Третьяковки. История одного шедевра.
15.45 Премьера сериала «Симфонические тайны».
16.15 Клуб путешественников.
17.00 Мультфейерверк.
17.45 «Один на один».
18.15 Счастливый случай.
19.05 Погода.
19.10 «Офицеры» Х.ф
20.50 Киноафиша.
21.00 Время.
21.35 Программа передач.
21.40 «Сегун» .Заключительная серия.
22.45 Лыжи. Чемпионат мира.
23.15 Футбольное обозрение.
23.55 «Ожидание полковника Шалыгина» Х.ф
1.35 Программа передач.

«РОССИЯ»

8.00 Мультфильм.
8.35 «Фрам - полярный медведь».
9.25 «Лотерейные новости».
9.40 Пилигрим.
10.05 Доброе утро, страна.
10.45 Присяга.
11.00 14.00 Вести.
11.15 Русское лото.
11.55 «Аура голубой планеты».
12.00 Книжная лавка.
12.25 Чемпионат мира по лыжным видам спорта.
13.30 Человек на земле.
14.20 «Молодой Пикассо».
15.15 «Виктория». Фестивалю солдатской песни - 10 лет.
16.20 «Сад культуры».
16.45 «Ничего, кроме...».
17.00 Волшебный мир Диснея.
18.00 Весь мир.
18.45 Телескоп.
19.25 Караоке по-русски.
20.00 Зеркало.
21.00 «Репортаж ни о чем».
21.10 Погода на завтра.
21.15 «Чистое небо». Х.ф
23.10 «К-2» представляет: «Колизей».
0.05 «У всех на устах».
0.20 У Ксюши.
0.50 Рек-тайм.
1.05 «Суета вокруг рояля»

РИО

14.30 Ток-шоу «Сделай шаг».
15.25 Спорт недели.
15.55 М/ф.
16.55 «Европа плюс» представляет.
17.40 «Самарские автомобили» представляют.
18.00 Телемагазин.
19.05 Дорожный патруль.
19.20 «Обозреватель».
20.00 «Фитиль».
20.20 Х/ф «Солдат Иван Бровкин».
22.05 «ОСП-студия».
22.55к «Список смертников» Х.ф
23.35 «Партийная зона».

УЧИЛИЩЕГА АТА - АНАЛАР КИЛГӘЧ...

«Яшьләр арасында тәрбия эшен көчәйтергә кирәк». Норлаттагы 99 нчы профессиональ училище укучылары ата - аналарының гомуми җыелышында бу фикер кызыл җеп булып сызылды. Ә моңа нигез юк түгел. Узган ел училищеда укучылар тарафыннан эшләнгән 4 жинаятьтә катнашучылар әлеге уку йорты укучылары булганнар. 12 укучы вак хулиганлык кылган, 20се исерткеч әчемлекләр куллануы өчен район эчке эшләр бүлегенә китерелгән. Милициядә учетта торучылар саны да кимү ягына бармый. Җыелышта катнашкан район прокуроры ярдәмчесе Д.В.Сәмигуллина китергән бу фактлар һәм, гомумән, соңгы вакытта балигъ булмаганнар арасында жинаятьчелекнең артуы ата - аналарны уйланырга, үз балаларын тәрбияләүгә житдиерәк карарга мәжбүр итәр, мөгаен.

Әлеге чарада катнашкан район үзәк шифаханәсе дерматологы Н.С.Шикова чыгышы да махсус ата - аналарга исәпләнгән иде. Үсмер кызларны һәм малайларны тәрбияләү, аерым алганда сәламәт яшәү рәвешен тәэмин итәрлек женси тәрбия күнекмәләрен өйрәтү, шулай итеп, аларны венерик авырулар йоктырудан кисәтү һәм башкалар.

Балаларның дәрестән соңгы вакытларын кызыклырак итү, шуна юнәлдерелгән үтемле педагогик алымнар куллану училище педагогларының ата - аналар белән берлектә башкарылырга тиешле эшләр - район мәгариф бүлеге методисты Г.Д.Әһлиуллина үз чыгышында төп игътибарны шуларга юнәлдерде.

Файдалы җыелыш бу. Шундый очрашулар ешрак оештырылсын иде, дип таралыштылар биредән ата - аналар.

Р.МИНАПОВА.

Укып чыккансың икән - кайтарып та бир

Безнең китапханәгә төрле яшьтәге кешеләр мөрәҗәгать итә - картлар да, мәктәп балалары да. Уку залында алар яңа килгән газета - журналларны караштыралар, контроль эшләрен эшлиләр, рефератлар язалар. Абонемент бүлегендәге китапларны өйгә биреп җибәрәбез. Һәм менә шунда безнең проблемаларыбыз башлана да инде. Безгә бит укучыларның да күпсанлы ихтыяҗларын кайгыртырга кирәк, китап фондыбызны да югалтуларсыз саклыйсы килә. Китаплар бер айга бирелә, ә укучыларның үтенече буенча ул срокны озайтабыз да. Әмма арада китапханәдән алынган китапны еллар буе өендә тотарга, хәтта бөтенләйгә үзендә калдырырга мөмкин дип санаучылар да бар. Андыйларның күп мәртәбәләр исләренә төшереп тә нәтиҗә булмагач, өйләренә дә барабыз, башка чаралар да кулланырга туры килә.

Бурычлыларыбыз НУРБның Советская урамындагы тулай торагында аеруча күп. Аларның күбесе анда пропискада гына торалар, ә яшәү урыннары башка җирдә һәм аларны эзләп күпме мәшәкатьләнәбез.

Әйе, китапханәгә язылуы жиңел - паспортыңны алып килеп күрсәтәсең дә, эшең бетте. Әмма биредән китап алып киткәндә сез үз өстегезгә зур жаваплылык та алуыгызны онытмасагыз иде. Әле китапларны эшкә яраксыз хәлгә китерүчеләр күпме тагын. Андый очракта гаепле кеше ул китап урынына китапханә шуңа тиң дип тапкан башка китап китерергә яки эштән чыккан китап бәясен унлата түләргә тиеш. Алары «Китапханәдән файдалану кагыйдәләре»ндә язылган.

Н.ТАРАСОВА,
район үзәк китапханәсенең баш китапханәчесе.

Спорт

Өчесе дә - Чулпаннан

7 - 9 февральдә Бөгелмә шәһәрендә 15 - 17 яшьлекләр арасында грек - рим көрәше буенча республика беренчелегенә ярышлар үтте. Анда сайлап алу ярышлары нәтиҗәләре буенча безнең районнан да өч үсмер үткән иде. Егетләрнен өчесе дә - Владимир Давыдов, Илгиз Әндәржанов, Ринат Нуретдинов - Чулпан көрәш мәктәбеннән иде. Чулпанлылар мондый ярышлардан читтә каламы соң инде?! Менә бу юлы да яшь көрәшчеләр турнирда уңышлы чыгыш ясадылар: В.Давыдов һәм И.Әндәржанов үз үлчәү авырлыкларында икенче урынны, ә Р.Нуретдинов авыр үлчәүдә 5 нче урынны яуладылар. Ярышка егетләрне тренер Р.Сәмигуллин әзерләде. Хәзер алар якташыбыз Бакиров призына уздырылачак ярышларга әзерләнәләр.

С.РАСЫЙХОВ.



КОТЛЫЙБЫЗ!

*Киекле авылында яшәүче кадерле әниебез **Хатирә Гата кызы Җәдитовага** 15 нче февральдә 72 яшь тула. Әни, чын күңелебездән туган көнең белән котлыйбыз, озын гомер, шатлык, ак бәхетләр, ныклы сәламәтлек телибез.*



Гел шатланып яшә, әни, хәсрәт күрмә,
Тыныч булсын һәрчак күңелең.
Бәрәкәтле, матур тормыш сиңа,
Кояшларга тиңе гомернең.
Озын гомер бирсен ходай дибез,
Кояш сиңа бирсен яктылык,
Балаларың гына түгел, оныкларың
Китерсеннәр сиңа яхшылык.

Иң изге теләкләр белән кызлары Чәчәк, Галия, Сания, улы Нәҗип һәм кияүләре.

Иске Әлмәт авылында яшәүче кадерле улыбыз **Нияз Нургаяз улы Җамалетдиновның** 18 февральдә, оныгыбыз **Илназның** 3 мартта туган көннәре. Аларны бәйрәмнәре белән котлап, киләчәкләренең бәхетле, куанычлы, сәламәтлектә үтүен телибез.

Котлы булсын сезнең туган көннәр,
Без барыбыз шушы теләктә.
Һәрвакытта шат елмайсын йөзегез,
Бәхет өстәп безнең йөрәккә.

Әти - әнисе, гаиләсе, туганнары.

Шулай да була шул ул

Ярлы булса да, комсыз түгел

Мексика таксисты Мануэль Лубиан комсыз түгеллегенен матур үрнәген күрсәтте. Ул машинасының арткы урындыгында берәүнен 53 мен Америка доллары салынган чемоданын онытып калдыруын күрә. Ул әлеге таркау пассажирны эзләп китә һәм, нихаять, таба. Акча хуҗасы Боливия сенаторы булып чыга. Мехико урамнарында иске «фолксваген»да кешеләр йөртүче бу таксист хәтта мондый очракта үзенә бирелә торган бүләктән дә баш тарта.

Очып барып җитмәсә дә...

Америка эшмәкәре Стив Фоссет һава шарында беркайда да туктамыйча Җир шарын әйләнеп чыгарга ниятләгән иде. Ләкин гөмбәздәге һаваны җылытырга ягулыгы бетү сәбәпле, ул Һиндстан җиренә төшеп утырырга мәжбүр булды. Ләкин моңа чаклы инде ул 6 тәүлек, 2 сәгать 49 минут һавада булып, 16 мең чакрым юл үтеп, Атлантик океанны кичкән, 15 дәүләт тупрагы аша үткән иде. Бу - һава шарында 1995 елда америкалылар Абруццо һәм Брэдли куйган рекордтан бер сәгатькә артыграк. Моңа чаклы инглиз Брансон һәм Француз Пекарде һава шарында Җир шарын әйләнеп чыгарга омтылыш ясаган булганнар, ләкин техник сәбәпләр аркасында уңышсызлыкка очраганнар. Фоссет очышы - шундый өченче омтылыш икән. Җир тирәли әйләнеп чыга алмаса да, ул очкан һава шары Вашингтонның авиация һәм космонавтика музеена куелачак.

(«Мәдәни жомга»дан).

Ишетмәсән ишет

Ташлар дәвалый

Борын заманнардан бирле кешеләр ташларны үз иткәннәр: юлга чыкканда үзләре белән алганнар, асылташлардан бизәнү әйберләре ясаганнар, бер - бер сенә бүләк иткәннәр, мәхәббәт билгесе итеп муеннарына такканнар, күз тиюдән, сихер - бозыктан шуның белән сакланганнар. Ташларга игътибар хәзер дә кимеми.

Һиндстанда бүгенге көндә дә ташлар белән дәвалыйлар, һәм ул алдынгы алымнарны берсе санала. Иң әһәмиятлесе, ташлар кеше сәламәтлегенә зарар итми. Аларны тапарга да, вакларга да, ачытырга да, эчергә дә кирәкми, бары тик тәнеңә якын урында йөртү генә сорала, кесәңә салып куйсаң да ярый.

Мәрҗән җәрәхәтне бетерүдән ярдәм итә, тын кысылуны киметә.

Аметист ташы нерв авыруларын дәвалауда ярдәм итә.

Лазурит йокысызлыктан дәвалый. Энҗе һәм зәбәрҗәт күңел төшенкелегеннән, эч пошудан файдалы.

Ай ташы кешене тормышка кайтара, дөньядан күңел кайтудан саклап кала.

Зәбәрҗәт хәтерне яхшырта, фикерләү дәрәҗәсен арттыра.

Фирәзә баш авыртуларын бетерә.

Кызыл якут йөрәкне дәвалый.

Нефрит ташы бөерләрнең эшчәнлеген яхшырта.

Хризопраз бәхетсезлекләрдән, куркыныч хәлләрдән саклый.

Зәңгәр якут (сапфир), алмаз, топаз, зәбәрҗәт, энҗе ташлары эпилепсия, экзема, хатын - кыз, сары авыруларын дәвалауда ярдәм итә.

Энҗе, зәбәрҗәт, зәңгәр якут ташлары белән бөерләрне, сидек юлларын дәвалыйлар, бөердә җыелган ташларны кудыруда файдаланалар. Шикәр авыруына каршы да әлеге асылташлар кулланыла.

Кызыл якут, мәрҗән, топаз, ай ташы, песи күзе кан бозылганда, кешене паралич сукканда, йокысызлык вакытында, буыннар, бөерләр авыртканда киң файдаланыла.

Зәбәрҗәт, якут, юлбарыс һәм песи күзләре ташлары кан басымын төшерә, кешенең холкын йомшарта.

Асылташлар турында сөйләүче, аларның серләрен ачкан язмалар, китаплар житәрлек. Әнә Соломон патша үзенең кадерлесенә жилләрне дә жилкәнләрдәй, холыкны да ягымлы итеп үзгәртердәй, кыргый жәнлекләрне аулаганда да үз кодрәтен күрсәтә ала торган аметист, мәхәбәттә бәхет китерүгә, ир белән хатын арасында бәхәсне, ызгыш - талашны бетерүгә ия, атлар белән сәүдә иткәндә булышлык күрсәтүгә сәләтле фирәзә асылташын бүләк иткән. Песи күзе кешенең мал - мөлкәтен, камил акылын һәм сәламәтлеген саклауда зур урын тоткан. Диңгез буендагы зәңгәрсу яшькелт суны хәтерләткән берил күзгә ак төшүдән, яман авырулардан саклаган һәм сәяхәткә чыгучының изге юлдашы булган. Төрле төсләргә ия агат хуҗасы дошманнары китереп чыгарган бәлаләрдән саклаган кала, жир тетрәүләрдән исән - имин чыга. Гомумән, һәр кеше үзенең ташын белергә тиеш. Бәлки, учлап - учлап дарулар эчкәнче, үзебезгә тиешле ташларыбызны сайлап, табып, аларны кулласак, гомер юлларыбыз шул асылташлар кебек матурлана, ямьләнә, яшәү мәгънәсе дә арта төшәр иде.

(«Мәдәни жомга»дан).

Белдерүләр

Акцияләр сатып алабыз

«Татнефть» АҖнең Б категорияле,
«Сургутнефтегаз» АҖ,
«ЛУКойл НК» АҖ,
«ЛУКойл - Лангепаснефтегаз» АҖ,
«ЛУКойл - Урайнефтегаз» АҖ,
«ЛУКойл - Когалымнефтегаз» АҖ,
«Ноябрьскнефтегаз» АҖ,
«Газпром» РАҖ акцияләрен.

Безнең адрес: «Сервистехинвест» ЧИФ. К.Маркс ур., 12 (ишеге яннан). Тел.: 2 - 19 -30.

Сатабыз

1995 елгы 2106 двигателе белән 1983 елгы ВАЗ - 2103. Тел.: 5 - 28 - 62.

***

Иж - Юпитер мотоциклы, кыймммәт түгел. Тел.: 2 - 28 - 11 (кичке 5тән соң).

***

Ашыгыч төстә Бауман ур, 73 адресы буенча йорт. Мунчасы, гаражы, коесы, 11 сутый жире бер. Тел.: 2 - 25 - 28 (теләсә кайчан).

***

Ашыгыч төстә «Москвич - 412 ИЭ», кыймммәт түгел. Адрес: Степан Разин ур., 9 (теләсә кайчан).

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның сишәмбе, жомга көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм жәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, жаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2071 данә Заказ № 5740